Бөтендөнья балалары, дуслашыгыз!



Сабантуй

БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘР ГАЗЕТАСЫ

11 декабрь 1991 ел. № 98 (4286).

Бәясе 3 тиен.

ЗУР БУ ДӨНЬЯ, ГАҖӘП КИҢ БУ ДӨНЬЯ!


Сибгат ХӘКИМ

* * *

Зур бу дөнья, гаҗәп
киң бу дөнья,
Узар әле анда күп
давыл,
Һич охшамас ләкин
дөм-караңгы,
Ташлап чыккан иске
йортка ул.

Зур бу дөнья, гаҗәп
киң бу дөнья,
Давыл җиңәр көче
бар аның;
Сукмакларда һич
өзелмәс кеше,
Үлән басмас ишек
алларын.

Зур бу дөнья, гаҗәп
киң бу дөнья,
Җылы хәбәр китер,
хат калдыр,
Өйдән өйгә, илдән
илгә ашык,
Соңга калма, ашык,
шатландыр.



МИҢА бүген Сибгат Хәким җитми. Аның олылыгы, абруе, сабыр акылы, йомшак тавышы, җылы сүзләре җитми. Бу тынгысыз, борчулы һәм мәрхәмәтсез заманда бигрәк тә. Ансыз узган утырышларга, җыелышларга, бәйрәмнәргә, тантаналарга һаман да өйрәнә алмыйм әле. Бауман урамындагы 19 нчы йортка барсам, коридордан Сибгат ага киләдер кебек. Аккош күленә барып чыксам, чәчәкләр, каеннар арасыннан тавыш-тынсыз гына Сибгат ага пәйда булыр төсле. Тукай һәйкәле янында уза торган шигърь бәйрәмендә шигъри бәйгеләрне әле дә Сибгат ага башлап җибәрер сыман. Бәйрәм саен шагыйрьләр арасыннан аны эзлим.

БЕЗГӘ бүген Сибгат Хәким җитми. Газета-журнал битләрен актара башласам, аның ялкынлы сүзе җитми, митингларда аның үтемле чыгышлары җитми, мәҗлесләрдә аның тапкыр тостлары җитми. Татар дөньясындагы бүгенге бөек үзгәрешләргә иң сөенгән кеше Сибгат ага булыр иде. Татарстанның бәйсезлеге өчен көрәшүче дә, яңа милли мәктәпләргә, яңа газета-журналларга фатиха бирүче дә ул булыр иде. Аның тыйнак һәм йомшак тавышы тамак төбе белән кычкыручыларның тавышын шунда ук күмеп китәр иде.

ТАТАРГА бүген Сибгат Хәким җитми. Яшь шагыйрьләргә аның дустанә мөнәсәбәте, аталарча кайгыртуы, акыллы киңәшләре җитми. Сәнгать кешеләренә — җырчыларга, композиторларга, артистларга да җитмидер ул. Барыбыз да аңа тартылды, аның белән киңәште, аннан җылы сүз көтте. Язучылар даирәсендә, сәнгать дөньясында, хәтта югары оешмаларда да аның сүзенә колак салдылар, аның киңәшен тоттылар, аның сүзен тыңладылар. Фикер алышуларда, бәхәсләрдә соңгы сүзне ул әйтте. Сибгат Хәкимнең шул сүзе җитми бүген.

ХАЛЫК шагыйренең китапларын актарам, шигырьләрен укыйм, җырларын тыңлыйм. Шатлыкларны да, борчуларны да аның белән уртаклашасы килә. «Их, Сибгат ага булса!» — дигән чаклар еш була.

МИҢА бүген Сибгат Хәким җитми!

Роберт МИҢНУЛЛИН.



Балачакта әйбәт иде:
Чакыра идек елап,
Алдыра идек сорап,
Үтәтә идек теләкне
Төрле юлларын сайлап.
Башкачарак хәзер эшләр,
Чакырсаң да дәшмиләр,
Сорасаң да бирмиләр,
Еласаң да килмиләр...

Радик ЗЫЯТДИНОВ.
Бөгелмә. 5 нче урта мәктәп.

* * *

Уйный да ул, җырлый
да ул
Бик кечкенә гармуны.
Күңелләрне биләп алды
Муса Маликов моңы.


Розалия ХӨРМӘТУЛЛИНА.
Актаныш, Байсар мәктәбе.

ТУГАН ЯГЫМ

Авылым янында урман —
Керсәң, чыгарлык түгел.
Кызарып пешкән җиләк-
ләр
Ашап туярлык түгел.

Күк куяннар йөгерешә
Куаклардан куакка!
Шатланып әйтәләр сыман:
— Хуш киләсез кунакка!

Эльвира ХӘЙРУЛЛИНА.
Бөгелмә. 5 нче урта мәктәп.



Олы да соң, дәү дә соң
Тау чаклы бар гәүдәсе;
Аяклары — бүрәнә,
Шәрык кунагы әнә.

Туктаусыз тора биеп,
Саумы, дип, башын иеп,
Кошларны сәламли ул.
«Көньяктан сәлам!» —
ди ул.

Алия НУРИСЛАМОВА.
Байлар Сабасы.

ГӨЛЛӘРЕМ

Аллы-гөлле алкалары,
Бөтен өйне яктырта.
Гөлләрнең шул чәчәкләре
Күңелләрне балкыта.

Гөлназ БАҺАУТДИНОВА.
Кукмара, Березняк.

КҮЗ

Инде минә күз житте,
Кошларым очып китте.
Сагынып искә алырга
Җырларын бүләк итте.

Эльвира ФӘЙЗРАХМАНОВА.
Балтач, Сосна.

ӘНИЕМНЕ ЯРАТАМ

Минем дә, әнием кебек,
Гел макталасым килә.
Кешеләрне сөендереп,
Гел шатланасым килә.

Гөлчәчәк ФАРАКШИНА.
Әлки, Ургагар.



Бик кечкенә этебез бар,
Исеме аның — Шарик,
Көне буе тәгәри ул,
Түп-түгәрәк шар кебек.

* * *

Бөтен дөнья уйга чумган,
Барысы тынып калган.
Бакчадагы кошчыклар да
Тәмле йокыга талган.

* * *

Урманнар, кырлар өстенә
Ява җепшек ак карлар.
Ак күбәләкләр очканын
Хәтерләтәдер алар.


Хәниф ХӘКИМОВ.
Әтнә, Күәм.

ГӨЛНАЗ

Ак җәймәсен пөхтә итеп,
Ул җәеп куйган күптән.
Рамнарын да сөртеп алган,
Гөлләргә сулар сипкән.

Табак-савытны чистарт-
кан,
Бөтен керләрне уган.
Кем ул, диеп баш ватма-
гыз —
Гөлназыбыз бик уңган.

Чулпан МӨХӘММӘТГАЛИЕВА
Саба.



Остазым турында хатирәләр

Сибгат Хәким исемен ишетүгә, хәтерем төпкелендә сугыштан соңгы 40 еллык иҗади гомерем җанлана. 1986 ел. Бөек Тукаебызның тууына 100 ел тулуы белән истәлекле ул. Тарихи бәйрәмне Татарстанда гына түгел, бөтен ил, дөнья күләмендә матур итеп уздырдык. Ә шушы елның 3 июль көне тирән кайгы алып килде: мөхтәрәм шагыйребез Сибгат Хәким белән хушлаштык. Минем өчен ул көн икеләтә фаҗигале: ун ел элек нәкъ шул көнне газиз әнкәемне җирләдем...

Әле дә истә: Сибгат Хәкимнең үлеме алдыннан аңа Татарстанның халык шагыйре дигән абруйлы исем бирелде. Сөенечле хәбәрне хастаханәдә бергә каршыладык. Янында карап-багып күпме йокысыз төннәр уздырган хәләл җефете Мөршидә апа, иренең хәле яхшыра төшкәч, мине вакытлыча аның бүлмәсендә калдырып, үзенең өйдәге эшләрен рәтләп килергә кайтып китте. Ял көне иде бу. Татарстан радиосы сәнгать осталарының концертын тапшыра. Ике җырның берсе Сибгат Хәким сүзләренә язылган. Авторның йөзенә нәзакәтле нурлар йөгерә. Үзе дәртләнеп концерт тыңлый, үзе тыйнак-сабыр гына тансык шатлыгын уртаклаша: **«Орденнарым да бар, мактаулы исемнәрем дә... Әллә ни исем китми аларга. Гомерем буе төпкә җигелеп эшләвемне, янып иҗат итүемне беләм. Ә менә миңа халык шагыйре дигән дәрәҗә бирелүен ишеткәч, әллә нигә каушап калдым. Бу бит — гомеремнең заяга узмавына, минем бөтен иҗатыма халык биргән иң абруйлы, иң югары бәя. Димәк, мин бәхетле. Бүтән берни дә кирәкми».** Остазымның талчыккан, моңсу-уйчан йөзләре яктырып-ачылып китте. Эчке бер тирән кичереш, көчле дулкынлану тәэсире иде бу.

Хәтерем күгендә янә шагыйрь белән бәйле мизгелләр яңара.

1947 ел. Август. Ленинградта демобилизацияләнеп, Казан университетына укырга килдем. Яшәргә урын юк. Тулай тораклар җитешми. Фатир җайлаштырырга кесәм такыр. Тимер юл вокзалында кунып йөрим. Карточка белән аласы 500 грамм икмәк тә кайчак чиратым җиткәнче бетеп куя. Нишләргә соң? Шул мәл Казанда танышкан фронтташ шагыйрь Сибгат Хәким әйткән сүзләр ярдәмгә килә: **«Син, Мәхмүт, андый очракларда миңа юл тот. Бары-югы уртак булыр»,—** дигән иде ул хәл-әхвәлемне аңлаткач. Адресын да язып бирде. Тәвәккәлләп шунда юнәлдем. Бөтен гаиләсе белән хуш күреп, якын туганыдай каршылады Сибгат абый. Җылы аш, кайнар чәй тәнгә иңгәч, күңел күтәрелеп китте. Шагыйрь абый үз итеп сөйләшә, киңәшләрен бирә, яңа язмалары белән таныштыра. Өйдәгеләр миннән берәр шигырь укуымны сорыйлар. Өйдә нарасыйлар булгач, «Чебиләр» исемле шигыремне, нәни малай кыяфәтенә кереп, яттан сөйләдем. Ике яшьлек улы Рафаэль минем кыланышлардан егыла-егыла кычкырып көлә. Сөйләвем аңа бик кызык булып тоелды, күрәсең.

1948 елның апрелендә 25 яшь тулды миңа. Шул айда җыентыгым да дөнья күрде. Сибгат абый булышмаса, басылып чыга алмый иде ул. «Сизәсеңме, Мәхмүт, Сибгат Хәким ничек игелекле сиңа. Рәхмәт йөзеннән туган көнеңә дәш үзен»,— дип киңәш бирде фатир хуҗасы. Үзем хуҗаны тыңлыйм, үзем эчемнән генә: «Нишләп килсен ул миңа ял көнне?! Сибгат Хәким ул атаклы Курск сугышларының яу батыры, танылган олы талант иясе. Ә мин шагыйрь булырга хыялланучы шәкерт кенә»,— дип уйлыйм. Шулай да тәвәккәлләп чакырдым Сибгат абыйны. Килде. Атаклы гармун остасы Фәйзулла Туишев туган көнемә бүләк иткән тальяным телләренә басуым булды, кунак җырлап җибәрде. Аңа хуҗам кушылды. Сибгат Хәким сүзләренә язылган, ул елларда халык арасында киң танылган «Фазыл чишмәсе», «Таң атканда», «Юксыну» җырларын автор катнашында кат-кат башкардык. «Кара нинди гади һәм эчкерсез кеше икән Сибгат Хәким дигәннәре!» — дип шаккатты фатир хуҗасы. Шул көннән алып Сибгат абый минем олы дустыма әверелде. Һәр чыккан яңа китабын истәлек итеп бирә барды. Шунысы кызык: автографына «иптәш» сүзен кертмичә калдырмый иде.

Әйе, Сибгат Хәким минем иҗат юлымда иң күп ярдәм иткән язучыларның берсе ул. Рәхмәтем чиксез зур аңа!

Хәким дигән кеше булган, диләр...
Булган түгел, бар ул һаман да.
Бүлешә ул кайгы-зарыбызны
Әремдәй чат ачы заманда.
Күлле-Киме күрке — газиз Ана
Безгә бүләк иткән моңлы бала
Йолдыз булып яна күңелдә.
Сибгат Хәким, димәк, яши һаман,
Шигъри каһарман ул бүген дә!..

Мәхмүт ХӨСӘЕН.

Рәсемдә: фронтовик шагыйрьләр С. Хәким, М. Хөсәен, Ә. Давыдов.

КӨРӘК ЭШЛӘҮ ГЕНӘ ҖИТМИ

Балык Бистәсе районы Олы Елга урта мәктәбе укучыларының хезмәт сөючән булулары инде күпләргә билгеле. Шулай да бүген аларның кайбер эшләре турында аеруча мактап сөйлисе килә. Мәсәлән, алар җәй көннәрендә чөгендер үстереп, колхозга тонналап чөгендер уңышы җыеп тапшыру белән бергә, үзләренең мәктәп яны тәҗрибә участокларында помидор, чөгендер, кишер үстереп авыл халкына саталар. Карлыганнары да бай уңыш бирә аларның. Карлыган үсентеләре дә үстереп саталар. Узган елларда ел саен җиләк-җимештән варенье кайнаталар иде. Ә быел, шикәр комы булмагач, мәктәп ашханәсе өчен варенье әзерли алмый калдылар, викторияләрен лагерьда ял итүче укучыларга һәм балалар бакчасына биреп бардылар.

Җәй көннәрендә Олы Елга мәктәбе чәчәккә күмелеп утыра. Ә көз көннәрендә укучылар шул чәчәкләрнең орлыкларын җыеп авыл халкына саталар. Бакчаларда чәчәк күп булса, авыл да бик матур күренә дип санайлар алар.

Менә хәзер уку елы дәвамында да укучыларның эшләре җитәрлек. Кызлар кечкенә «сувенир» мендәрләр тегеп ярминкәләргә алып чыгалар. Элек мендәр тегү өчен мехны Казанның 3 нче тегү фабрикасыннан алып кайтканнар. Ә быел укучыларның конкурентлары күбәйгән.

Кызлар эшләгәндә малайлар нишли икән соң? Алар да тик тормыйлар. Ындыр табагы өчен, ярминкәләрдә авыл халкына сатар өчен калай көрәкләр эшлиләр.

Укучыларның хезмәт дәресләрендә үз көчләре белән мәктәп өчен акча эшләүләре әйбәт, әлбәттә. Әмма бу дәресләргә дә аз гына үзгәреш кертергә кирәктер дип уйлыйм мин. Мәсәлән, тегү тегәргә, кадак кагарга кечерәк сыйныф укучыларын да өйрәтергә кирәктер. Ә инде өлкәнрәкләргә үзләре теләгән эш буенча эшләргә мөмкинлек бирергә кирәк. Колхозда бу мөмкинлекләр зур. Олы Елга урта мәктәбе коллективы да шушы фикердә тора.

Гөлназ КЫЯМОВА,
КДУ студенты.

ГИМНАЗИЯДӘ — КИЧӘ

Казанның 2 нче гимназиясендә шушы көннәрдә татар халык авыз иҗатына багышланган кичә уздырылды. Бу кичәне гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Зөлфия Гатауллина әзерләде. Кичә татар халкының традицион уеннары белән башланып китте. «Түгәрәк», «Әбәк-чәбәк», «Капкалы», «Йөзек салыш», «Кул чабыш», «Гөлмәрфуга» уеннары элек-электән яратып уйналганнар. Ул уеннар татар халкының шат, шаян, күңелле икәнлеген күрсәтеп торалар. Хәзер инде аларның күбесе онытылып та беткән. Менә шул уеннарны халыкка кире кайтару өстендә күп эшли Зөлфия.

Кичәгә IX А, Б классы укучыларыннан оештырылган курай, кубыз ансамбле дә ярдәмгә килде. Ансамбль җитәкчесе, музыка белгече Ринат Хәбибуллин балаларда музыкага тирән мәхәббәт хисе тәрбияләп кенә калмый, аларны оста, кешенең күңел кылларына чиртерлек итеп халык уен коралларында уйнарга да өйрәтә. Мәсәлән, ул көнне дә Мөслим Зәйниев, Илнур Хәбиров, Әнвәр Заһретдинов курайда, Венера Гатина кубызда сыздырдылар. Татар халык көйләрен оста итеп башкардылар. Рәмзидә Илмакачеваның биюе, Алмаз Галиевнең шигырь сөйләве, Рәмия Шакированың җырлавы да тамашачылар күңеленә хуш килде.

Ул көнне гимназия укучылары күңел ачып кына калмадылар, әби-бабайлары уйнап үскән уеннарны да өйрәнделәр.

Фәиз МИРСӘЕТОВ.

ҖЫРЛАП ЯШИБЕЗ



Быел Шәңгәлче мәктәбенең урта мәктәп булып үзгәртелүенә 25 ел тулды. Биредә эшләп килүче интернациональ дуслык клубына да тиздән 20 ел тула. Кан кардәшләребез — болгарлар турында күп материал тупладык. Илебезнең төрле почмакларында яшәүче, Эстония, Казахстан, Кыргызстан, Молдовадагы яшьтәшләребезнең гореф-гадәтләре, мәдәнияте буенча материаллар җыябыз, сувенирлар алмашабыз, кунакларга йөрешәбез. Язгы каникулда Карелиягә бардык, көзге каникулда Ульяновскига сәяхәт ясадык. Аң-белемнәрне киңәйтү өчен төрле кичәләр, очрашулар еш үткәрелә. Район укучыларын чакырып дүртенче мәртәбә слет үткәрдек. Тәҗрибәләр уртаклаштык, җырладык, биедек — бик күңелле булды.

Әнә 8 класс укучысы Рәйсә Таҗиева җырлый, баянда 9 класстан Маулина Алсу көйләрне бик оста башкара.

Гөлмәрьям ФӘСТИЕВА.
Түбән Кама.
Рамил ӘБДЕЛМӘНОВ
фоторәсеме.

Сибгат ХӘКИМ



Бер күрергә күптән уйлап йөргән
Көннәрнең мин барам каршына.
Исәнмесез, көннәр,
Исәнмесез, гөлләр...
Мин карарга белмим кайсына.
Гөлләргә кул бирәм,
Көннәргә юл бирәм,
Көннәргә юл бирәм,
Көн алышына, дөнья алышына.

Ул көннәргә килеп җитәр өчен
Мин кайчаннан бирле ашыктым.
Исәнмесез, дуслар,
Исәнмесез, кошлар...
Мин гашыйкмын, Җиргә гашыйкмын.
Дусларга кул бирәм,
Кошларга юл бирәм,
Нинди аяз, нинди ачык көн...



Урманнарга керсәң, сызгырып кер,
Селкенмәгән агач калмасын;
Сукмакларын уят, аланнарын,
Кошчыкларын уят аннан соң...

Кошлар канат җилпемәгән төштә
Юллар озын, юллар шомлырак.
Сайрасыннар бар да шашып-шашып,
Урман эче торсын шаңгырап.

Онытылмасын өчен кошлар монда
Һәр агачка җырын уйгандыр...
Калын урман, күпне күргән урман,
Уйландыра алсаң, уйландыр.

БӨТЕНЛӘЕМ БЕЛӘН

Бөтенләем белән Җирнеке мин,
Минем барлык нәсел-нәсәбем —
Игенчеләр. Җирдән төртеп чыга
Һәрбер юлым, һәрбер әсәрем.

Иген уңса — җыр да тиз язылды,
Күрми узсам җирдә яңаны,
Колхозчылар шелтә белән миңа
Басулардан бармак янады.

Көтмәгәндә матур хәбәр килсә,
Әйтик, Әлмәт яки Буадан,
Республикабызның көрәштәге
Данлы көнен котлап куанам.

Бөтенләем белән җирнеке мин,
Минем барлык нәсел-нәсәбем —
Игенчеләр. Җирдән төртеп чыга
Һәрбер юлым, һәрбер әсәрем.



Туган якта күреним генә үрдән,
Шатлыгыннан арыш ду кубар,
Сөенчегә бүләк өмет итеп,
Кырлар буйлап йөгерер дулкыннар.

Кырлар буйлап йөгерер дулкыннар.
Кара-кучкыл... шундый төс кергән.
Йөгерә алар юлдан кайтып килгән
Атлар, машиналар өстеннән.

Анда авыл, әнкәй торган авыл,
Ветпунктны гына үтсеннәр...
Ул дулкыннар безнең иске зират
Коймасына ятып үксерләр.







ОЗЫН ТОЛЫМЛЫ НӘНИ ГҮЗӘЛЛӘР

Озын чәчле нәни гүзәлләребезнең бергә җыелганнарын күргәнегез бар идеме әле сез? Юктыр, мөгаен. Ә менә 23 ноябрь көнне «Озын толым» конкурсына килгәннәр бу бәхеткә ирештеләр. Чөнки ямьле табигатьтән көч алып, озын чәчләрен чишмә суы белән юып үстергән бу кызлар бәйрәмнең бизәге булып тордылар. Татар дөньясында беренче тапкыр үткәрелә торган «Озын толым» конкурсында катнашырга килгән бу кыю кызлар кемнәр соң? Әйдәгез әле, алар белән танышып китик.

Алар арасында иң кечкенәсе Арча кызы Илмира Бариева. Аңа бары тик 9 яшь кенә әле. Илмира биергә ярата.

Әлмәт районы Бишмунча урта мәктәбеннән Алена Уразаевага 10 яшь. Ул бик матур итеп рәсемнәр ясый, бии, җырлый. Җәй көннәрендә әнисенә шикәр чөгендере карап үстерүдә булыша.

Ә менә Чаллы шәһәренең 25 нче урта мәктәбеннән VI класс укучысы Лариса Устинова үзен яхшы биюче буларак күрсәтте. Ул дүрт ел инде биючеләр түгәрәгенә йөри икән. Рус мәктәбендә укуына карамастан бик матур итеп татарча сөйләшә. Конкурска Лариса үзенең татар теле укытучысы Хаҗәр апасы Гәрәева белән килгән. Хаҗәр апасының да, шактый гына олы яшьтә булса да, бер генә ак чәче дә юк әле һәм чәч толымнары да яшьләрнекеннән ким түгел.

Балык Бистәсе районы Шумково авылының V класс укучысы Ләйсән Гайсина шигырьләр яза икән. Конкурста тамашачыларга ул үзенең яраткан җырын бүләк итте.


Чаллы шәһәреннән килгән тагын бер кыз — Гөлнара Нуретдинова. Ул 45 нче мәктәпнең II классында укый. Гөлнара бик матур итеп рәсемнәр ясый. Мәктәпнең һәр стена газетасы аның рәсемнәре белән чыга.

Күрдегезме инде, озын чәчле нәни гүзәлләребезнең нинди икәннәрен. Билгеле, әлегә озын чәчле апалары белән ярыша алмыйлар алар. Әмма киләчәктә без аларны да «Озын толым» конкурсының иң гүзәл кызлары арасында күрербез.

Озын толым — матурлык, чисталык, пөхтәлек билгесе. Татар кызларының милли горурлыгы булган, табигать биргән бу байлыкны кадерләп үстергән кызларга сокланмаслык түгел.

Сез дә, «Сабантуй»ны укучы дусларым, чәчегезне кистерергә ашыкмагыз. «Озын толым» конкурсы әле кабатланыр.

Г. КЫЯМОВА.



РӘСЕМНӘРДӘ:
Ләйсән Гайсина, Алена Уразаева, Ландыш Газизова, сәхнәдә озын толымлы гүзәлләр.

Е. КАНАЕВ фоторәсемнәре.

ЯКЫНЛАША ЕРАК АРАЛАР

«Добрыня Никитич» теплоходы Әстерхан портына якынлашты. Биш көн буе эшсез бару һәркемне ялыктырган иде инде, шунлыктан барысы да, зур түземсезлек белән тизрәк җиргә төшү мизгелләрен көттеләр. Кич булу сәбәпле, биредә искиткеч матур манзара иде, аллы-гөлле утларга күмелгән порт бинаkлары, краннар тезелеп утыра. Идел дулкыннары шавы астында горур кала җәелеп ята. Менә капитанның: «Правый швартовый!» дигән тавышы яңгырады һәм теплоходыбыз җайлап кына дебаркадерга килеп туктады.

Без — Казан дәүләт университеты студентлары, татар халык хоры составында Әстерхан өлкәсенә гастрольгә дип килүебез. Беренче ел гына баруыбыз түгел, узган елның да нәкъ шушындый кояшлы көз көнендә бирегә килеп төшкәч, бик җылы каршы алганнар иде безне Әстерхан дусларыбыз.

Менә бүген дә порттан ук автобусларга төяп алып киттеләр дә җылы, якты кунакханәгә урнаштырдылар.

Икенче көнне, шәһәр белән танышканнан соң, Җәмәл дигән татар авылына киттек.

Автобус тузанлы юлдан җилдерә. Тирә-якта — җәйрәп яткан басу. Урыны-урыны белән генә бездәге камышлыкны хәтерләткән дүрт-биш метрлы гигант үсемлекләр урманы күренеп кала. Безнең якларбдагы кебек җиргә кытлык юк монда. Эшләүче кеше генә булсын: уңышны икешәр, хәтта өчәр тапкыр алырга була бер җәйдә. Помидорны, бәрәңгене, кишерне икешәр тапкыр утырталар, редис, суган ишеләрен әйтеп тә торасы юк.

Җәмәл авылында безне бик әйбәт каршы алдылар. Юкса, монда әле күптән түгел генә безнең якташлар — Казан филармониясе артистлары да булып киткән икән.

...Казанда хәзер яңгырлар ява торгандыр инде, бәлки, беренче кар да төшкәндер. Монда исә кояшның кыздыруына түзәр әмәл юк. Көн саен су коенабыз, кызынабыз. Арзан гына бәягә карбызкавыннар да тулып ята.

Күп урыннарда булырга өлгердек без шушы берничә көн эчендә. Бөтен Әстерхан өлкәсенә билгеле булган Киләче авылы белән дә таныштык. Әстерханның үзендәге «Дуслык» татар оешмасы белән дә элемтәләрне ныгыттык, медицина институтының зур залында концерт та куйдык. Әстерхан мәчетләре белән таныштык. Тәэсирләр тулып ташкан иде инде. Иң мөһиме — яңа дуслар таптык. Киләчәктә дә шулай һаман аралашып, хәбәрләшеп яшәрбез дип сөйләштек.

«Ямьле булса да туган җир, сагындыра туган ил», диләр. Кайтыр юлга чыккач, һаман еракта, артта кала барган гүзәл җәй шәһәреннән шулай тиз китүгә үкенмәдек.

Теплоходыбыз кайтканда озаграк — бер атна чамасы кайтты. Моңарчы география дәреслекләреннән генә укып белгән шлюзларны да күрдек, «Генерал Ватутин»ның өске палубасында күңелле кичәләр оештырдык, ә көндезләрен исә рәхәтләнеп кызындык.

Кайтыр юлга чыгуның бишенче көнендә Иделдә шторм башланды. Тау-тау дулкыннар теплоходыбызны йомычка урынына селкетте. «Диңгез авыруы»на бирешүчеләр моны бик авыр кичерде, әлбәттә. Хәзер инде өченче яруска менеп кызынып та булмый башлады. Кая ул! Зәһәр җилләр тәнне өтеп кенә ала. Хәтта җылы курткасыз палубага чыгып булмый.

Ниһаять, республикабыз җиренә килеп кердек. Шторм да бераз басылган кебек булды.

Кичен палубага чыктык. Ачы җил исә, кыш җиле. Еракта-еракта Казан портының аллы-гөлле утлары җемелди. Кызыллы-аклы маяк утлары шаярышып күз кысалар, гүя алар безне: «Туган җирдән аерылып шулай озак торырга ярыймыни, салкын булса да, үзегезнеке бит»,— дип, дусларча гына шелтәлиләр кебек иде...

А. САБИРОВ.

Олуг затны сагынганда



Шагыйрьнең кече улы, бүген бөтен татар халкына мөстәкыйль Татарстан өчен армый-талмый көрәшүче буларак танылган мөхтәрәм галим, җәмәгать хадиме Рафаэль Хәким берничә ел элек миңа әтисенең көндәлек дәфтәрләрен күрсәткән иде. Соңгы дәфтәрнең иң соңгы битендә 1986 ел,16 январь көне белән тәмамланган язма... Мин аны күчереп алдым. Ни өчен дигәндә, нәкъ шул бит кенә шагыйрьнең үзе вафат булганнан соң дөнья күргән китабына (аңа мәкаләләр, публицистик язмалар, көндәлекләре тупланган) нигәдер «сыймый калган» иде. Сәбәпләрен ачыклап тормыйм. Әмма әлеге юллар зур шагыйрьнең, остазның шәхесен тагын да калкурак ачарга ярдәм итә дип уйлыйм. Менә ул өзек: «Буран, салкын, сулау авыр... Язучылар союзында җыелыш булды. Өйгә хәтле Рәдиф култыклап алып кайтты. Сугыштан яралыларны алгы сызыктан шулай алып чыгалар иде. Фронт искә төште. Үзем дә кайчакта алып чыккаладым. Әдәбият — алгы сызык. Хәзер



үземне алып чыгалар. Минем өчен алгы сызыклар бетте. Әз генә дә үкенмим, борчылмыйм, ике фронтта да ахырынача сугыштым...» Татарстан халык шагыйрен күреп, укып белгән, аның яшәү, иҗат рәвешен тойган бер генә кешене дә битараф калдырмас үләренә ярты ел кала язылган бу юллар... Әмма бик яхшы хәтерлим, аннан соң да шагыйрь иҗат итте әле — шигырьләр, мәкаләләр язды, радио һәм телевидение тапшыруларында теләп катнашты — шулай булмыйча, бу ел бит Сибгат ага өчен иң мөкатдәс ел — Тукай, Шигърият бәйрәме елы иде. Аксакалны өенә озатулар; аның инде хәле бетеп, туктап ял итүенә җайлашып, урамнардан бергә атлаулар тагын да булды. Шигырьләр сөйләнде, төрле сүзләр, фикерләр уртаклаштык... Чыннан да, ил торгынлык елларыннан яңага, үзгәрешләргә атларга җыенган чорда өлкән шагыйрь арыган, авыру хәлдә кебек иде шул... Тик бу — барыннан да бигрәк, халык өчен, милләт, татар теле өчен борчылулардан иде; әлеге тоталитар режим чын мәгънәсендә кешеләрне өметсезлеккә үк төшергән иде! Әмма шунысы да хак: ул елларда язган шигырь, җыр, поэмалары да халыкның киләчәгенә гаҗәеп ышаныч, горурлык, Тукайча олылык, затлылык белән сугарылган бит. Бу — көрәш, яшәүнең хаклыгына ышану һәм тынычланып, васыять калдыруы иде шагыйрьнең. Язмышына эндәшеп, аңа үпкәсе юклыгын әйтеп, бары тик бер генә үкенечен әйтә бит Сибгат ага:

Әнкәмнән мәхрүм итсәң дә,
Телемнән итмә ятим.

Бу — туган тел, халык язмышы — Тукайлар рухының дәвамы, яшьләрдә яшәве өчен борчылу... Шул ук 1986 елның 24 апрелендә Казан телевидениесе Тукай юбилее алдыннан әңгәмә-очрашу оештырды. Анда Сибгат ага һәм Уфадан шагыйрьнең иң яраткан каләмдәш энесе Нажар ага Нәҗми катнашты.

Тапшыру-әңгәмәне мин алып бардым. Ике аксакал шагыйрь, гүяки ярышып, гаҗәеп дәрәҗәдә камил, затлы чыгыш ясады ул көнне: шигырьләр укылды, заман, шигърият, Тукай турында фикерләр әйтелде... Иң әһәмиятлесе, 70 ел дәвамында үләргә хөкем ителсә дә, төрле яктан кысылса, кагылса да, халкыбызның яңадан, «үз көленнән яңарачагына» зур өмет белән яндырып, кискен сөйләде алар. Бигрәк тә авыру хәлдә дип белгәнебез Сибгат ага бу тапшыруда шундый бер илһам, көч белән балкыды ки, хәзер уйлап, «безгә әйтәсе сүзләрен әйтеп бетергә, уртаклашырга ашыккан икән ул көнне» дип куям. Тапшырудан соң, бергәләп, рәсемгә дә төштек... Бу тапшыру телевидение фондында калгандыр әле.

Истәлекләр... Аксакал үзе исән чакта да мин аның иҗаты турында мәкаләләр яздым, шигырьләр багышладым, күп кичәләрдә бергәләп чыгыш ясадык. Аккош күлендә күрше булып, аралашып, гәпләшеп 15 ел бергә яшәлде — әмма иң кадерле, аңа лаек сүзләрне таба алдыммы? Ай-һай! Аның турында гади генә истәлек, вакыйгалар сөйләү, хатлардан юллар китерү — болар аз кебек. Гомумиләштереп, аның безнең чынбарлыктагы урынын билгеләп, чын мәгънәсендә әдәби һәм кеше буларак портретын җанландырган язмалар булачак әле. Бу көннәрдә, 80 еллыгы уңае белән дә күп язылыр алар. Шулай булмый: илле елдан артык татар шигърияте өчен — әле нинди елларда! — өзлексез янып, өстән «боерганны гына» түгел, боермаганны да башкарып, чын шигърилек — димәк ки, халыкка ышаныч, мәхәббәт мәктәбен дә тудырган шагыйрь бит ул Сибгат ага. Шуңа күрә үзе дә халык мәхәббәтен исән чагында ук күреп, белеп, сөенеп яшәде шагыйрь, хәтта мәктәпләрдә үзенең әдәби музейларын, укучылар, укытучыларның даими игътибарын күрде. Әмма татар мәктәпләре бетеп, урысча укытылуны бик авыр кичерде, шәһәр мәктәпләрендә очрашуларга бармас булды — анда тел ватып, ямьсезләнеп сөйләшүне яки манкортларча кыланышларны әрнеп кабул итә иде ул. Шуңа да аның белән Арча педучилищесында очрашуларда булганда, чын татарча аралашу аны әсәрләндерә, ул сөенечен яшерә алмый иде. Шундый бәхетле минутлары да була иде шагыйрьнең!

Әлбәттә, халыкның, мәктәпләрнең, туган тел язмышын ул безгә караганда күбрәк аңлый, эчтән яна, сызлана иде. Нинди каршылык: 45 ел партиядә торып, КПСС кушканны сүзсез үтәргә тиеш булган шагыйрь җаны кушканны — халык турында дөреслекне тик яшеренеп, читләтеп әйтергә мәҗбүр иде. Менә кайда иде аксакал әдипләребезнең фаҗигасе! Шагыйрьнең 70 яше тулган көннәр. 1981 елның декабре. Мин — шагыйрьләр секциясе җитәкчесе буларак — юбилей комиссиясендә (рәисе — Гариф ага Ахунов). Парторг Ринат Мөхәммәди, ул чак Чаллы язучылары җитәкчесе Разил Вәли, Роберт Миңнуллин, Сибгат аганың Чаллыда, Түбән Камада узган кичәләрендә бергә идек. Яшьләр һәм аксакал. «Җидегән чишмә» һәм шагыйрь моңы... Халык мәхәббәте һәм васыятьләр. Сорауларга җаваплар.

Бездә ташып торган шаянлык, дәрт белән төрле мавыгуларга аның сабыр гына кушылулары, үпкәсез генә сүзләре... Кичәләрнең искиткеч күркәм рухта узуына сөенече... Мәҗлестә Җәлил язмышы һәм үзе турында уйлары белән балаларча беркатлы уртаклашулар... Бу көннәр шагыйрьнең шигъри триумфы булу белән бергә, яшьләргә әйтәсе сүзләренең дәвамы иде бит! Самолетлар очмыйча аэропортта уздырган сәгатьләрдә дә аның сүзләре җитди, саллы, халык һәм шигърияттән аерылгысыз иде. Сирәк хәл: 25 елга якын аралашып, Сибгат агада мин бер генә «мәгънәсез көлкеуен» сүз озайту, арзанлы мәзәк, анекдот яки кемнедер рәнҗетү, саксызлык, тупаслык ишарәсе күрмәдем, ишетмәдем. Хәтта тумышы белән Уфа ягыннан булганнарга да шундый булды. Үзе чын зыялылар затыннан иде шул, гали тәрбияле, зирәк акыллы иде... Шул ук 70 еллык юбилее кичәләре Тукай клубында да, пединститутта да, туган авылы Күлле Кимедә дә дәвам итте... Мәктәптә әдәбият укытучысы Луиза Сәмигуллина оештырган музей да барыбызга да ошады, шагыйрь туган нигездә тирән мәгънәле сөйләшүләр, авылдашларының табигый ихтирамын күрү, хатыны Мөршидә апа, улы Рафаэль, оныгы Искәндәр белән бәхетле төс белән урамнардан узулар — барысы да матур истәлек хәзер. Бүген радио аша:

Минем таныш өянкеләр,
Сезгә баш ияр кемнәр? — дип Вафирә ханым җырлавы да шул көннәрдән калган бер моң агышы кебек! Ә инде 1986 елда без Күлле Кимегә янәдән (75 еллыгына) килдек... Әмма бу юлы инде шагыйрьнең үзеннән башка.



Истәлекләр... Кадрлар кебек алмашынучы сурәтләр... Менә тагын бер фоторәсем. 1970 елның гыйнварында төшкәнбез. Сибгат ага — уртада. Аның тирәсендә — 60 елларда әдәбиятка килгәннәрдән бер төркем: Равил, Ренат, Гәрәй, Рөстәм, мин... Әлегә торгынлык еллары. Үзгәрешләр әле бик еракта, киләчәктә атачак таң кебек — алда, алда... Без дә әле алданган, күпне аңлап та бетермәгән, ил, халык тарихын әле йөрәк белән төшенмәгән яшелләр, яшьләр, әмма иҗади дәрттә янган чая «әтәч»ләр... Киләчәк нинди булыр? Остаз безгә әйткәннәр тормышка ашармы? Дөнья куласасы бер әйләнеп тә басармы тагын? Әллә бар чынлык, яшәү рәвеше, идеаллар, тарихи аң, акыл — шул газеталар өйрәткәнчәме? Бердәнбер дөрес юл шулмы? Әле алдансак та, ялгышсак та, гаеп түгелдер: без бит — хис, шигырь балалары.

...Рәсемгә карыйм. Яшьлеккә канатлар куйган остаз янына сыенганбыз. Әйе, ул яшьләргә ышана. Күп әле, күп аның шәкертләре, бу рәсемгә сыймаганнары да... Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Рәшит Әхмәтҗаннар... Роберт Миңнуллиннар... Лена Шагыйрҗан, Нурия Измайловалар... Бик күпләр!

Әмма без нинди булырбыз? Аның өметен акларбызмы? Дан өчен, урын, премияләр өчен яшәүгә йөз тотып, шигърияткә хыянәт итмәбезме? «Алтын шылтыравы астына» төшмәбезме? Идеалларга тугры калырбызмы, халыкка кирәкле булырбызмы? Бу сорауларга җаваплар да алда. Әлеге рәсем-фото бу турыда сөйләми. Әмма ул инде тарих. Бер буынның сәер дуслык чоры ядкаре. Дисбе кебек... Бисмилласы — Сибгат ага...

Хәер, үзе исәндә татар шигыренең дә бисмилласы булып торды бит ул мөбәрәк дисбедә — безнең Сибгат агабыз. Сагындыра . . .

Рәдиф ГАТАШ.

Баш мөхәррир Роберт МИҢНУЛЛИН

РЕДКОЛЛЕГИЯ: Шәүкәт ГАЛИЕВ, Атлас ГАФИЯТОВ, Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ, Ләлә ГЫЙМАДИЕВА (җаваплы секретарь), Госман САДӘ (баш мөхәррир урынбасары), Асия ЯРУЛЛИНА, Фоат ХӘМИДУЛЛИН.

Адрес: 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2, «Сабантуй».
Телефоннар: 53-07-95; 53-07-94.
Чәршәмбе һәм шимбә көннәре чыга.

«Сабантуй» — ВЛКСМның Татарстан рескомы һәм Татарстан Балалар фонды газетасы. 1924-1990 елларда «Яшь ленинчы» исеме белән чыкты.



Татарстан Балалар фондының счеты. — 707101.
Индекс — 54124.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты типографиясендә басылды.

Заказ 1083